ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

Миграция сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасында башкарыла торган эш турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Э.А. Зарипованың һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсе башлыгы А.А. Кузнецовның миграция сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасында башкарыла торган эш турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Э.А. Зарипованың һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре буенча идарәсе башлыгы А.А. Кузнецовның миграция сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасында башкарыла торган эш турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Чит ил гражданнарының законсыз хезмәт эшчәнлеге дәрәҗәсен киметү, шулай ук легаль булмаган хезмәт миграциясенә каршы тору һәм этносара низагларны булдырмау максатларында Татарстан Республикасында башкарма хакимияте органнарының миграция сәясәте өлкәсендә мәсьәләләрне хәл итү буенча хезмәттәшлеген оештыру эшен активлаштырырга.

2.2. Татарстан Республикасы хезмәт базарына квалификацияле чит ил белгечләрен җәлеп итү буенча нәтиҗәле чаралар комплексын әзерләү максатларында аларны Татарстан Республикасында эшләү өчен чакыру шартларын анализларга.

3. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Агымдагы елда чит ил гражданнары тарафыннан, шулай ук чит ил гражданнарына карата кылынган җинаятьләр саны артуга китергән сәбәпләрне

һәм шартларны анализларга, андый җинаятьләр санын киметү буенча профилактик чаралар кабул итәргә.

3.2. Чит ил гражданнарының миграция исәбенә фиктив алынуы фактларын һәм миграция өлкәсендә законнар таләпләрен үтәмәүнең башка фактларын ачыклау эшен дәвам итәргә.

3.3. Чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның вакытлыча яшәп тору үзәгендә тору шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Хезмәт базары торышын һәм эш көченең чынбарлыктагы ихтыяҗларын мониторинглау эшен дәвам итәргә.

4.2. Татарстан Республикасында чит ил гражданнарының адаптациясенә һәм интеграциясенә ярдәм итү максатларында чит ил гражданнары һәм эш бирүчеләр белән мәгълүмати һәм оештыру-методик эшне активлаштырырга.

5. Татарстан халыклары Ассамблеясенә Татарстан Республикасында милли диаспоралар вәкилләре белән милли мәсьәләләр аркасында барлыкка килгән низагларны кисәтүгә, чит ил гражданнары тарафыннан хокук бозуларны профилактикалауга, этносара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне ныгыту өчен шартлар булдыруга юнәлдерелгән эшне активлаштыруны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның 2 – 5 пунктлары үтәлеше барышы турындагы мәгълүматны 2021 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына җибәрергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 26 ноябре
№ 739-VI ДС